СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

**12 декабрь, 2025 ел** | **№ 25**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2016 елның 08 августындагы 78 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 05 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2016 елның 08 августындагы 78 номерлы карары (16.10.2019 № 317, 27.10.2025 № 5 карарлары редакциясендә) белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Муниципаль районны социаль-икътисадый үстерүнең озак сроклы өстенлекләре» 4.4 бүлеген 24 абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Халык тормышы сыйфатын яхшырту, районның сәламәтлек ныгыту һәм туристик-рекреация потенциалын үстерү буенча стратегик планлаштыру кысаларында төп чараларның берсе булып «Кызыл Тау» күпфункцияле спорт-савыктыру комплексын төзү тора.

«Кызыл Тау» проектын гамәлгә ашыру сәламәтлек саклау, спорт, туризм һәм ял өлкәсендә хезмәтләр спектрын киңәйтергә мөмкинлек бирәчәк, яңа эш

урыннары булдыруга, инвестицияләр җәлеп итүгә һәм сәламәт яшәү рәвеше үзәге буларак Биектау районы имиджын ныгытуга һәм милли тиңдәшлекне саклап калуга ярдәм итәчәк.

Спорт инфраструктурасын алга таба үстерү, югары казанышлар спортына ярдәм итү һәм халыкны физик культура белән актив шөгыльләнүгә җәлеп итү максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Урманче поселогында Татарстан Республикасының теннис буенча җыелма командасы спортчылары өчен тренировка базасын булдыру өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора.

Әлеге проект региональ дәрәҗәдәге профессиональ теннисчылар әзерләү өчен заманча һәм югары нәтиҗәле инфраструктура булдыруга юнәлтелгән. База теннис буенча Татарстан Республикасы җыелма командасының ел әйләнәсендә уздырыла торган күнегүләр өчен төп объект булачак, ул спортчыларны югары нәтиҗәләргә ирешү өчен кирәкле шартлар белән тәэмин итәчәк. Моннан тыш, район территориясендә яңа спорт объекты булу төрле яшьтәге халыкны физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк, бу үз чиратында халык сәламәтлегенә уңай йогынты ясаячак, социаль активлыкны арттырачак һәм үсеп килүче буыннарда сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру өчен стимул булачак.»

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып, бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов